

РӘСЕМХАНӘ



Декоратив композиция. 1992




Декоратив кувшиннар. 1993



Урман иясе. 1992



«Зилант». 1992





Суга барам. 1995

# Хәмит ЛАТЫЙПОВ

Меңнәр таптап узган аяк астындагы гап-гади балчыктан берсеннән-берсе сәрле илаһи сыннар пәйда була. Борыннарын югары чөйгән горур аккошлар, гаҗәеп агач-үсентеләр, сырларын кабарткан усал җәнлекләр... Бу әкияти дөньяга чумсаң, үзеңне ниндидер бер сихри урманда итеп тоясың. Әйтерсең дә тирә-якта киек мыжгып тора, агач-куаклар төрле татлыдан-татлы җимешләрдән сыгылган. Ләкин бу оҗмах гүзәллеге кинәт челпәрәмә килер дә кәкре-бөкре агач ботаклары арасыннан шүрәле килеп чыгар кебек. Биредә моң да, шом да — барсы да бар. Хәмит Латыйповның иҗаты әнә шулай әллә нинди билгесез дөньяларга алып керә, балачакның әкият илләренә әйди.

Хәмит Латыйпов 1949 елның 5 мартында Пермь өлкәсенең Губаха шәһәрендә дөньяга килә. Әти-әнисе шул елны ук Башкортстанның Илеш районы Бүләр авылына күчеп кайта. Малай берберартлы иң газиз кешеләрен югалта — 9 айлык Хәмитне калдырып, әнисе гүр иясе була, 13 яшьтән әтисез кала.

Җиде-сигез яшьтән балта эшенә өйрәнә башлаган Хәмит бу һөнәрне тулысынча үзләштерү өчен Уфада махсус училище тәмамлый. Төрле төзелешләрдә эшли, арытаба Уфа сәнгать училищесында белем ала. «Агач эшкәртү сәнгате остасы» дигән дипломга ия булгач, ул яңа төзелеп килүче Чаллы шәһәренә юл тота. Бик күп корылмалар бизәүдә, сыннар, паннолар тудыруда катнаша. 1988 елдан Туймазыда фарфор һәм фаянс фабрикасында эшли, шамот-утташ, пыяла, керамикадан катлаулы сыннар иҗат итә. 1991 елда Хәмитнең Санкт-Петербургта «Тат-арт» күргәзмәсендәге «Болгар» дип аталган композициясе сәнгать белгечләренең һушын ала. Бөтендөнья татар конгрессына багышланган махсус күргәзмәдә катнаша.

Аның иҗатына көнчыгыш сәнгатендәге кебек чагу төсләр гаммасы, заманча дизайн, татар этнографиясе һәм халык иҗаты элементларына мөрәҗәгать итү хас. Оста нинди генә темада эшләмәсен ул тудырган сәнгать җимешләреннән миллилек бөркелеп тора.

М. МӘХМҮТОВ



Уйлану. 1995